ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　КАРАР

09.07.2021　　　　　　　　№ 649

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 22.06.2012 ел, № 679 карарына үзгәрешләр кертү турында

30.04.2021 N 120-ФЗ, 19.12.2016 N 433-ФЗ, 31.07.2020 N 268-ФЗ номерлы Федераль Законга таянып, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Административ регламентларны раслау турында» 2012елның 22 июнендәге 679 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.5 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында мондый җир кишәрлеге турында белешмәләр булганда);»;

2 нче кушымтаның 2 пунктындагы пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) чит дәүләт территориясендә бирелгән белем һәм (яисә) квалификация турында, галимнәр турында һәм галим исемнәр турында документлар һәм укытуны узуга бәйле документлар, һәм аларның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсе;»;

түбәндәге эчтәлекле б_1 пункт өстәргә:

«б_1) хәрби һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белемнең хәрби белем бирү оешмалары тарафыннан бирелә торган белем һәм (яисә) квалификация турында, галимнәр турында документлар, шулай ук 1992-1995 елларда Россия Федерациясе территориясендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан бирелгән;»;

24 Административ регламентның 2.5 пунктындагы 10 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе; гражданлык хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясенең консул учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклыклар;";

16 Административ регламентның 2 пунктындагы в, г пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның рус теленә

нотариаль таныкланган тәрҗемәсе; гражданлык хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясенең консул учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклыклар;";

2 нче кушымтаның 1 пунктын е пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт эшчәнлеге, хезмәт стажы турында документлар (2020 елның 1 гыйнварына кадәр)».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Хәмзин